# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлеге составына керүче “Мамадыш” совхозы поселогында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча граждannар җыены нәтиҗәләре турында

№ 15

«19» ноябрь, 2021 ел

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 нче статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ санлы Татарстан Республикасы законының 35 нчестатьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлеге муниципаль берәмлеге» Уставының 23 статьясы, Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлегенең “Мамадыш” совхозы поселогында 2021 елның “19” ноябрендә узганү зарасалым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча түбәндәге сорау буенча граждannар җыены беркетмәсе нигезендә:

«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлегенең “Мамадыш” совхозы поселогы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган граждannарга, 1,2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2022 елда 400 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

- “Мамадыш” совхозы поселогындагы юлларны төзекләндерү (таш, торба һәм ком кулланып юлны төзекләндерү, шартнамә буенча эшләр өчен түләү);
- «Мамадыш» совхозы поселогында каты көнкүреш калдыклары контейнерлары өчен мәйданчыклар төзү;
- «Мамадыш» совхозы поселогында балалар мәйданчыгы сатып алу, урнаштыру;
-“Мамадыш” совхозы поселогы урамнары юлларын кардан чистарту һәм юлларны тигезләү;
- «Мамадыш» совхозы поселогында урамнарны яктырту объектлары урнаштыру һәм аларга хезмәт күрсәтү (урам яктырту лампалары һәм баганалар сатып алу, аларны урнаштыру, линияләргә һәм лампаларга хезмәт күрсәтү һәм шартнамә буенча эшләр өчен түләү):

Граждannар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 1921 кешекертелгән;

граждannар җыенында тавыш бирүдә катнашучылар саны: 985 кеше, 51,3% тәшкил итә:

Гражданнар җыенында катнашучыларның ачык тавыш бирү нәтиҗәләре түбәндәгечәбүленде:
«РИЗА» позициясеөчен 940 граждан тавыш бирде;
«КАРШЫ»позициясеөчен 45 граждан тавыш бирде;

Бәянителгәннәрнигезендә, халык җыены КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1.Гражданнарның үзарасалымакчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлегенең "Мамадыш" совхозы поселогында узган гражданнар җыенын - уздырылган, нәтиҗәләре - дөрес, дип танырга.

2. Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлегенең "Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлегенең "Мамадыш" совхозы поселогы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1,2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2022 елда 400 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

- "Мамадыш" совхозы поселогындагы юлларны төзекләндерү (таш, торба һәм ком кулланып юлны төзекләндерү, шартнамә буенча эшләр өчен түләү);
- «Мамадыш» совхозы поселогында каты көнкүреш калдыклары контейнерлары өчен мәйданчыклар төзү;
- «Мамадыш» совхозы поселогында балалар мәйданчыгы сатып алу, урнаштыру;
-"Мамадыш" совхозы поселогы урамнары юлларын кардан чистарту һәм юлларны тигезләү;
- «Мамадыш» совхозы поселогында урамнарны яктырту объектлары урнаштыру һәм аларга хезмәт күрсәтү (урам яктырту лампалары һәм баганалар сатып алу, аларны урнаштыру, линияләргә һәм лампаларга хезмәт күрсәтү һәм шартнамә буенча эшләр өчен түләү):

3. Әлеге карарны Кызыл Тау авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актларыРегистрына кертү өченҗибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Мамадыш муниципаль районы
Кызыл Тау авыл җирлеге Башлыгы,
Совет рәисе В.А.Гиззатуллина